**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**22.02.2022** № **04-05-29**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 23 нче мартында чыккан 04-14-41 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 18 нче ноябрендә чыккан “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы иҗтимагый совет турында” 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 23 нче мартында чыккан 04-14-41 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 12 нче маенда чыккан 04-14-64 номерлы, 2017 нче елның 9 нчы ноябрендә чыккан 04-14-162 номерлы, 2019 нчы елның 3 нче июнендә чыккан 04-05-59 номерлы, 2021 нче елның 13 нче декабрендәге чыккан 04-05-138 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары М.С. Ротарьга йөкләргә.

Рәис Р.Н. Сабиров